**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Жуково авыл җирлегенең Иоково торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**25 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлегенең Иоково торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Жуково авыл җирлегенең Иоково торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, локаль хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

-Иоково авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;

- Иоково авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү;
- Иоково авылында эчендәге юлларны төзекләндерү.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Н.П. Сапожников**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Жуково авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Сапожников**